# Урыны түрдә булды!

Әлеге китап ике тугандаш халыкның — татар белән башкортның — бөек җырчысы, илаһи моң иясе Фәридә Кудашева турында...

Язмамда мин Фәридә апаны олылау өчен матур сүзләр, чагыштырулар эзләп тормыйм, аның бөеклеге, фидакярлеге турында, фаҗигаләргә, даншөһрәтләргә бай вакыйгалар белән сугарылган язмышы, озын-озак гомер кичерүе, җырларының үлемсезлеге, ике халыкка да күрсәткән игелекле хезмәтләренең олылыгы хакында тәфсилләп сөйләргә дә җыенмыйм. Китапта алар барысы да бар. Үз эченә бик күп тирән фикерләр, уй-кичерешләр, матур-матур тасвирламалар, ихлас бәяләр, якты хатирәләр тупланган шушы китап Фәридә Кудашеваның бөеклегенә тагын бер дәлил булыр дип ышанам!..

Ходайның рәхмәте яусын, Фәридә апа белән миңа озак еллар якыннан аралашып яшәргә туры килде. Фикердәшләр дә, дуслар да булдык. Һәр күрешүебез, очрашуыбыз күңелемдә бетмәс-төкәнмәс уй-фикерләр, ихлас соклану хисләре, матур-матур истәлекләр калдырды. Шул очрашулардан алган тәэсирләрем әле булса җанымны җылытып тора...

Соңгы елларында Фәридә апа Казанда еш була торган иде. Аны бездә бик яраттылар, хөрмәт иттеләр. Мин биредә иң элек, әлбәттә, җыр сөючеләрне, тамашачыларны күз алдында тотам. Республика җитәкчелеге дә аны игътибарыннан читтә калдырмады: дәрәҗәле исемнәр дә алды, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе дә бирелде. Төрледән-төрле бәйрәмнәргә дә, зур-зур тантаналарга да олы кунак итеп чакырылды. Урыны түрдә булды!

«Таттрансгаз»ның игелекле җитәкчесе, якташыбыз Рәфкать Кантюковның Фәридә апага булган җылы мөнәсәбәтен аерым әйтеп китәсем килә. Олуг җырчыбызны ул һәрвакыт туганнарча каршы алды, олылап кунак итте, ял итәргә бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Очрашуларның берсендә, сүз иярә сүз чыгып, без аның белән Фәридә апабызның язмадагы бөтен җырларын да туплап, компакт-диск чыгарырга кирәк дигән фикергә килдек. Аңа кадәр җырчының бердәнбер дискы гына чыккан иде, анысы да сатуда булмады шикелле. Фәридә апа безнең тәкъдимгә бик сөенеп риза булды, билгеле. Үзенең архивыннан, Башкортстан һәм Татарстан радиосы фондларыннан, иске пластинкалардан, аерым шәхесләрдән җырларны җыю, аларны билгеле бер тәртипкә салу бер елга якын дәвам итте. Фәридә апа белән һәрчак элемтәдә булдык. Сораулар килеп туса, тиз генә аның үзенә шылтырата идем. Казандагы якын дусты Рафаэль Ильясовның да ярдәме бик зур булды. Нәтиҗәдә, Фәридә Кудашева репертуарындагы 100гә якын җырны бергә туплап, «Барс-Медиа» ширкәтендә компакт-дисклар чыгаруга ирештек. Без аны Фәридә апаның 85 яшендә, Уфада узган юбилей

кичәсендә бүләк иттек. Ә Уфага бару үзе бер истәлекле вакыйга булды. Фәридә апа гел шылтыратып торды, кемнәр киләалыр икән дип борчылды. Без Кантюков белән бергә барырга дип алдан ук сөйләшеп куйган идек. Юбилей көннәре җитәрәк, Фәридә апа тагын шылтыратты: «Ничә кеше килерсез икән?» — дип сорады. Үз чиратымда мин Рәфкатькә дәштем. Ул ике дә уйлап тормады: «Фәридә апага әйт, кирәк булса, җитмеш кеше барабыз!» — диде. Мин шушы сүзләрне җиткергән идем, Фәридә апабыз телсез калды. Аннары, һушын көчкә җыеп: «Роберт, алай итмәгез инде! Миңа ун урынга гына чакыру бирделәр, мин сезне кая утыртып бетерим? Ун кешедән дә артмасын инде!» — диде. Рәфкат тә килеште, ун кеше сыярлык кечерәк самолёт сөйләшергә булды…

Дәүләт Советы сессиясе утырышы бара иде, мин Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә Фәридә Кудашеваның юбилее турында, анда һичшиксез катнашырга кирәклеге турында, бара калсак, делегациянең югары дәрәҗәдә булырга тиешлеге турында язып, записка җибәрдем. Кунакка буш кул белән бармаска иде дигәнрәк сүзләр дә өстәдем. Тәнәфестә ул мәдәният министры Зилә Вәлиева белән икебезне чакырып алды. Шунда барысы турында да сөйләштек. Зилә рәсми делегация җитәкчесе булачак, дәүләт бүләге турында да сүз булды…

Без «Таттрансгаз» самолёты белән Уфага очтык. Мәдәният министры Зилә Вәлиева, мин, атаклы җырчыларыбыз Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Ильясов, яшь җырчы Айдар Габдинов, баянчы Ринат Вәлиев, скрипкачы Захар Штейнберг…

Казанга кайткач, Президентыбызга Фәридә апаның дисклары белән бергә кечкенә хат язып җибәрдем. Анда түбәндәге сүзләр бар иде: *«Хөрмәтле Минтимер Шәрип улы! Теге чакта Фәридә апа Кудашеваның 85 яшьлек юбилеена Сезнең фатиха белән Уфага баруыбыз бик дөрес һәм бик әйбәт булды. Бөтен Уфаны шаулатып-гөрләтеп кайттык. Фәридә апаны да, республикабызны да, халкыбызны да һәм, әлбәттә инде, үзебезне дә күтәреп кайттык. Сезнең Указ белән бирелгән «Фидакяр хезмәт өчен» медален тапшыру да бик урынлы, бик вакытлы булды. Халык бик матур кабул итте. Делегацияне премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева җитәкләве, Илһам Шакиров, Рафаэль Ильясов кебек мәшһүр җырчыларның булуы да бәябезне бермә-бер арттырды.*

*Безне бергә җыеп, оештырып алып барган Рәфкат Кантюковка зур рәхмәт. Ул безне бик күп проблемалардан коткарды. Рәфкат дигәннән, без аның ярдәме белән, Фәридә апаның бөтен язмаларын да диярлек туплап, биш компакт-диск та чыгардык. Сезгә шуларны җибәрәм. Әле тагын эзләп табасы, бераз эшкәртәсе җырлары калды, аларын да җыеп чыгарырга хыялланабыз. Мөмкин булса, берәр видеодиск та чыгарырга исәбебез бар…»*

Фәридә апа «Газовик»та ял итәргә ярата иде. Аның янынан Казандагы иҗатташ дуслары өзелмәде. Мин дә барып йөрдем. Көннәрнең берендә

Кайбыч районына күренекле җырчыбыз Галия Кайбицкаяга багышланган бер бәйрәмгә чакырулы идем. Шул хакта Фәридә апага да әйттем. Минем белән барырга ул бик теләп риза булды. Бәйрәм матур бер яланда узды, көн бик матур, халык бик күп иде. Казаннан килгән җырчылар да бихисап. Мин, халык алдына чыгып, котлау сүзләре әйттем. Ахырдан бу бәйрәмгә яраткан җырчыбыз Фәридә Кудашеваның да килүен белдердем. Халык аһ итте! Фәридә апаны сәхнәгә чакырдым. Әлеге көтелмәгән бәхеттән Кайбыч яланы гөр килеп алды. Мондый ихлас каршы алудан соң Фәридә апабыз, әлбәттә инде, бик дулкынланды. Шулай да матур-матур сүзләрен әйтә алды, аннары «Илдарым» дигән җырын җырлап җибәрде. Алдан ук колагыма: «Төшеп китмә, янымда гына тор!» — дигән иде. Җыр тәмамланганчы янында басып тордым. Халык белән туп-тулы җәйге ялан бөек җырчыны тын да алмый тыңлады. Сәхнәдән барысы да уч төбендәгедәй күренеп тора иде…

Фәридә апаның бер килүендә күңелемә әйбәт бер уй килде: аны видеога төшереп алырга кирәк! Санаторийның урыны — Идел буенда, көннәр — матур, Фәридә апа үзе — менә дигән әңгәмәдәш, рәхәтләнеп сөйләшеп була. Нигә сынап карамаска? ТНВга, Миләүшә Айтугановага шылтыраттым. Хәлне аңлатып биргәч, «Газовик»ка ул телевидение операторы Мөнир Залюшевны җибәрде. Ярты көн буена без Фәридә апа белән әңгәмәләшеп утырдык, табигатьтә, Идел буенда йөрдек. Мөнир барысын да камерасына төшереп барды. 2006 ел иде ул…

Фәридә Кудашева 90 яше тулырга ике ай калганда бу дөньядан китеп барды. 2010 елның 9 октябрендә, Уфаның томанлы, яңгырлы көзендә без аны соңгы юлга озатып калдык. Табигать белән күңелләрнең тәңгәл килүен кара син?! Бик моңсу булды, авыр булды. Бөек җырчыбызны соңгы юлга озатырга Казаннан Зилә Вәлиева, Разил Вәлиев, Равил Шәрәфи бардык. Матәм җыенында Уфаның бөтен җәмәгатьчелеге, Башкортстанның бөтен җитәкчелеге катнашты…

Казанга кайткач, «Газовик»та төшерелгән видеотасма турында М. Айтугановaның исенә төшердем. Шул тасма нигезендә без «Агыйделдә ак пароход» исемле телефильм эшләдек. Миңа калса, бик матур килеп чыкты. «ТНВ Планета» каналыннан әллә ничә тапкыр күрсәттеләр инде. Халык яратып карый, рәхмәтләр әйтеп шылтыраталар, хатлар язалар… Аның җырлары һаман яңгырап тора, Фәридә апа һаман да исән кебек…

Әлеге китап бөек җырчыбыз Фәридә апа Кудашева хакында. Аның язмышы, иҗаты, таланты, популярлыгы турында. Җәмәгатьчелекнең, халкыбызның аны яратуы, олылавы, аның җырлары белән яшәве турында… Халкыбызның җырчыга табыну дәрәҗәсендәге самими хөрмәтен миңа бик күп мәртәбәләр үз күзләрем белән күрергә, халык мәхәббәтенең шаһиты булырга туры килде. Ул илаһи мизгелләр күңелемдә иң кадерле истәлекләр булып саклана.

Фәридә апа һәрвакыт халык алдында, халык арасында, халкыбызның күңелендә булды. Казанга да ашкынып килә иде. Марат Шәриповның Агыйдел – Чулман – Идел буйлап оештырган сәфәрләренең берсен дә дияр-

лек калдырмады. Минем үземә дә ул сәфәрләрнең берничәсендә катнашу бәхете елмайды. Сәяхәтләрнең 2010 елдагысы исә бөек җырчыбызның 90 яшьлегенә багышланды. Фәридә апа әлеге сәфәргә җәмәгатем Клара белән мине дә дәште. Искиткеч фәһемле, эчтәлекле һәм истә калырлык сәяхәт булды ул. Алдан сизенгән кебек, бу сәфәрнең Фәридә апа өчен соңгысы икәнен белгән кебек, без аның юбилеен пароходта олылап уздырдык.

Шул пароходта Фәридә апа минем кулыма, алдан ук сөйләшенү буенча, архивында сакланган гәзит-журналлар, язмалар тутырылган бик авыр олы бер сумка тоттырды. Ул хәзинәне мин берничә ай өйрәндем. Әлеге китапка кергән язмалар нәкъ менә шулардан сайлап алынды. Барысын да кертеп булмады, билгеле. Китапның күләме сыйдырган кадәр генә, форматы туры килгән материаллар гына алынды. 2004 елны Уфадагы «Китап» нәшрияты «Фәридә Кудашева» исемле альбом-китап чыгарган иде. Күренекле башкорт шагыйре Хәсән Назар һәм шулай ук күренекле мөхәррир Галия Галимова төзеп чыгарган бу затлы китапны: «Хөрмәтле якташларым Клара белән Робертка — очрашу мизгелләре булып, озак елларга истәлек булып калсын!» — дип, Болгарга 2005 елгы сәфәребез вакытында Фәридә апа үзе бүләк итеп биргән иде. Башкорт, татар, рус телләрендә чыккан шул альбомдагы язмаларның бер өлеше әлеге китапта да урын алды. Аннары Сөембикә Кудашеваның (Фәридә апаның якын туганы, Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашның кызы) «Фәридә» исемле истәлекләр китабы бар. Сөембикә апаның рөхсәте белән, аның язмаларын да кертүне кирәк таптым. Чөнки анда җырчының тормышына мөнәсәбәтле кызыклы фактлар, Сөембикә апа үзе генә белгән кызыклы хәл-вакыйгалар тасвир ителгән.

Җәмәгате, моңдашы, сәхнәдәше Бәхтисез Фәридәне күз алдына да китереп булмый. Шуңа күрә китапка Бәхти Гайсин турындагы берничә мәкаләне дә кертү урынлы булыр дип исәпләдем. Фәридәнең тормышын, иҗатын бизәгән Бәхти китапны да бизәр, бөек җырчыбызның язмышын, образын күз алдына китерергә ярдәм итәр дип ышанам.

Китапны әзерләүдә Фәридә апаның якын дуслары, Уфада яшәүче галим, журналист Рәүф Идрисов һәм аның җәмәгате Венера Гыймазова бик теләп катнашты. Берничә ел дәвамында алар аның архивын тәртипкә китерде, матбугатта чыккан бөтен язмаларны, аңа килгән хатларны, документларны барлап чыкты. Фәридә апа турындагы истәлекләрнең дә бер өлеше алар тырышлыгы белән язылды. Әлеге язмаларның барысын да диярлек компьютерда бертуган сеңлем Люция Мөгаллим кызы Ходаймәтова бастырды, башкорт телендәгеләрен турыдан-туры татарчага күчерде. Рәхмәт яусын үзләренә!

Шулай ук бөек җырчыбызга булган олуг ихтирамы һәм игътибары, шушы китапны дөньяга чыгарырга мөмкинлек тудырганы өчен беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә дә олы рәхмәтләремне ирештерәм.

*Роберт Миңнуллин*



# Мәкаләләр, фикерләр